РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

***Постановление*** ***Карар***

11.04.2025 **Чистай шәһәре** № 76

Чистай шәһәр Башкарма комитетының «Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» 2016 елның 27 июнендәге 96 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт җайга салуы нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясын, «Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын эшләү һәм раслау тәртибен раслау хакында» Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2011 елның 26 февралендәге 34-ОД номерлы боерыгын үтәү өчен, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы, «Муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 18 сентябрендәге 675 номерлы карарларын үтәү йөзеннән, Чистай шәһәр Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай шәһәр Башкарма комитетының «Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» 2016 елның 27 июнендәге 96 номерлы карары белән расланган стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасына, кушымта нигезендә, 119-120 пункт өстәп, өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтына (http://chistopol.tatar.ru/) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай шәһәре Башкарма комитетының сәүдә, мәдәният, яшьләр сәясәте, спорт һәм туризм бүлеге баш белгече Ю. Ю. Әхмәтовага йөкләргә.

Шәһәр Башкарма комитеты
җитәкчесе И.Ф. Рәхимов

Шәһәр Башкарма комитетының
11.04.2025 № 76
карарына кушымта

## Чистай муниципаль районының Чистай шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасы

| № т/б | Стационар булмаган сәүдә объектының урнашу урыны | Сатыла торган товар ассортименты | Стационар булмаган сәүдә объекты тибы | Сәүдә урыннары саны | Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру чоры |
|---|---|---|---|---|---|
| 119. | Чистай ш., Скарятин бакчасы | Туңдырма | Киоск | 1 | сезонлы |
| 120. | Чистай ш., Скарятин бакчасы | Таиланд туңдырмасы, Аждаһа сулышы десерты, алкогольсез эчемлекләр | Киоск | 1 | сезонлы |